
Бүгенге санда:



Нурлат – төзелешләр каласы. 2 бит


# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга 7 август 2015 ел

№ 57 (10586)


**8 августка һава торышы:** аязучан болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил көнбатыштан, 4-5 м/с; температура көндез +24°С, төнлә +17°С

## КОТЛАУ

**Хөрмәтле төзелеш тармагы хезмәткәрләре!**

Һөнәри бәйрәмегез – Төзүчеләр көне белән чын күңелдән тәбрик итәм! Сезнең хезмәтне горурланып, шәһәр һәм районыбыз тормышының төп нигезе дип атарга була. Сезнең көндәлек карусыз хезмәтегез белән Нурлат заманча шәһәргә әверелде. Быелның башыннан гына да 11970 квадрат метр торак файдалануга тапшырылды, 15 йорт капиталь ремонттан соң яңа сулыш алды, төзүчеләр ярдәме белән авылларның инфраструктурасы да яхшыра тора. Һәр объектны вакытында тапшыру өчен, сез ял көннәрендә дә, бәйрәмнәрдә дә хезмәттә. Чөнки шәһәрлеләрнең уңай яшәве үзегезнең хезмәткә бәйле икәнлеген бик яхшы аңлыйсыз. Фидакарьлегегез өчен рәхмәт!

Төзүчеләр, хезмәтчәннәр! Сезнең эшегез гаять авыр, берүк вакытта үзегезнең казанышлар өчен горурлык та китерә. Өйләрегездә һәрчак җылы һәм җайлы, гаиләләрегез имин булсын, ә йөрәкләрегездә гомер буе уңышка илтүче чаткы сүнмәсен иде. Үзегезгә дә, якыннарыгызга да игелек һәм бәхет телим!

**Равил Кузюров, Нурлат муниципаль районы һәм шәһәре башлыгы**

## ФИЗКУЛЬТУРАЧЫЛАР КӨНЕ СЕЗНЕ КӨТӘ

**Шимбә, 8 августта** районда Физкультурачылар көне билгеләп үтелә. Бу уңайдан шикәрчеләр бистәсе стадионында зур бәйрәм оештырыла. Анда футбол буенча блиц-турнир, ветераннар арасында очрашу, пневматик мылтыктан ату, җиңел атлетика эстафетасы кебек ярышлар, концерт программасы көтелә. **Бәйрәм 10.00да башлана.**

# Авыл үссен өчен ярдәм бар




ӘНИЛЕ-УЛЛЫ ХӘЛИМ ҺӘМ ГӨЛСИНӘ САТДАРОВЛАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ГҮЗӘЛИЯ ЛОТФУЛЛИНА БЕЛӘН

**Бу көннәрдә Татарстан Республикасы лидеры Рөстәм Миннеханов республика кырларын карый, урак барышын шәхси контролендә тота. Ул берочтан республика президент программаларының үтәлеше белән дә кызыксына.**

Бу көннәрдә Якты Күл авылында яшәүче Сатдаровларның шатлыгы зур: гаилә фермасына килә торган юлларын ясап, бетон өслек түшәп куйдылар. Гаиләгә терлекчелек фермаларына кадәр юл төзү республика президент программасы ярдәмгә килде. Сатдаровлар – районда гаилә фермалары программасына беренчеләрдән булып кушылган, моның өчен бирелә торган 1 млн. сумнан артыклык республика һәм район ярдәменнән файдаланган гаилә. Бүгенге көндә 32 баш савым сыерлары, 40тан артыграк баш мөгезле эре терлекләре бар. Хуҗалыклары авылның читендә диярлек, елга буенда урнашкан, шуңа да юл булмауның кыенлыкларын шактый күрергә туры килгән. Хәзер исә 500 метрлы юл хуҗалыкны үзәктәге асфальт юл белән тоташтыра.

– Гаилә фермалары илебезне үзебездә җитештерелгән продукция белән тәэмин итүгә хезмәт итә. Бу юл исә гаилә фермасы өчен генә түгел, бөтен авыл өчен мөһим, - ди Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Гүзәлия Лотфуллина.

Гөлсинә һәм Хәлил Сатдаровлар да юлга сөенеп туя алмыйлар.

– Гаилә фермасы тоткач, мәшәкатьләр шактый, азык, тирес чыгару, сөтне урнаштыру өчен һәрчак яхшы юл кирәк. Хәзер эшләргә күпкә җайлырак булачак, юл өчен без республика һәм район җитәкчелегенә рәхмәтле, - диләр.

– Районда әлеге программа гамәлгә кергәнне бирле, бишенче гаилә фермасына шундый юл салынды инде, - ди районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин. – Узган елда "Нурлат сөте" хуҗалыгының Урта Чаллы бүлеге терлекчелек фермаларына да 200 метрлы юл ясалды.

Республикада бүгенге көндә тормышка ашырыла торган 30 республика президент программасының шактые авылларга һәм авыл кешесенең тормыш-көнкүреш һәм яшәү шартларын яхшыртуга юнәлтелгән. Һәм, ил кризис шартларында яшәүгә карамастан, аларның берсе дә туктатылмаган, барысы да эштә.

–Бүген республикада авыл хуҗалыгы предприятиеләре яшәсен һәм алга таба үсештә булсын өчен зур ярдәм күрсәтелә. Мәсәлән, узган елда Россия һәм Татарстан бюджетларыннан районның авыл хуҗалыгы предприятиеләренә 547 миллионнан артыклык ярдәм бүленде. Быел бу сумма 298 миллионнан артыграк, шуның 108 миллионы – Татарстанныкы. Шундый ярдәм булганга, авыл җитештерүчесе үз продукциясе белән республиканы туендыра ала да, – ди идарә начальнигы.

Татарстанда узган елдан участок ветеринария пунктлары төзү республика президент программасы да уңышлы эшләп килә. Әлеге программа буенча районда быел икенче участок пункты төзелеп, ишекләрен ачты. Быел ветеринария лабораториясе капиталь ремонтланды, дәүләт программалары ярдәмендә фермалар ремонтлана. "Нурлат сөте"нең Иске Чаллы авылы янында сенаж-силос траншеясы төзелеп бетеп килә...

– Республикада шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, гаилә фермаларын үстерүгә дә игътибар зур, - дип дәвам итә Ислам Салихович. – Югары технологияле гаилә фермалары барлыкка килү авыл кешеләрен эш белән тәэмин итү, җитештерүчәнлекне арттыру ягыннан бик файдалы булды. Бүгенге көндә бездә 41 гаилә фермасы бар, шуларның 12се – югары технологияле. 2012нче елдан бирле 2 дистәгә якын фермер төрле конкурсларда катнашып, грантларга ия булды. Ел саен шәхси ярдәмче хуҗалыкларында савым сыер асраучыларга республикадан финанс ярдәме күрсәтелә. Быел ул бер баш сыерга 3 мең сум тәшкил итәчәк, хәтта кәҗә асраучыларга да 1әр мең сум күләмендә ярдәм булачак. Моннан тыш, район халкы шәхси ярдәмче хуҗалыкларга бирелә торган ташламалы кредитның да файдасын күрә. Программа гамәлгә кергәннән бирле 661 кеше 227 миллион сум кредит алган, быел 76 кеше 17 млн.га ташламалы кредит рәсмиләштергән. Моннан тыш, авыл җирендә яшәүче яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү, яшь белгечләргә акчалата ярдәм күрсәтү һәм башка республика президент программалары уңышлы эшләп килә... Кыскасы, эшлим дигән кешегә дәүләт һәрьяклы ярдәм күрсәтергә әзер. Һәм болар алга таба да дәвам иттереләчәк әле, чөнки авыл хуҗалыгын үстерү – республикабыз лидеры Рөстәм Миннехановның игътибар үзәгендә.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**


Кредит на все случаи жизни

Выдаем деньги даже при наличии кредитов в других банках
Учитываем неподтвержденные доходы
Возраст заемщика до 80 лет

Нурлат, Карла Маркса, 19 | 8-19, ежедневно

ПРОБИЗНЕСБАНК (84345) 264-74

Лайф Финансовая группа

ОАО АКБ "Пробизнесбанк". Кредит выдается по усмотрению банка. 80 лет на момент погашения кредита. Реклама.

banklife.ru

Ген. лиц. №2412 от 28.04.2003 г.

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

САЙЛАУЛАР-2015

## Теркәү тәгәлләнә, агитация башлана

**Тавыш бирү көненә бер айлап вакыт калып бара.**

Бердәм тавыш бирү көненә ун көн кала нурлатлылар үз сайлауларын башта район һәм шәһәр территориаль сайлау комиссияләрендә, аннан бер атнадан соң – урында, үз сайлау участокларында башкара алалар. Тавыш бирү өчен бердәнбер таләп – гражданинның сайлаулар көне – 13 сентябрьдә катнаша алмавының нигезле сәбәбе булу. Аны исә гаризада күрсәтергә кирәк булачак.

ТР Президентын сайлауларда 4 кандидат катнаша: "Татарстан Республикасында Гадел Россия" сәяси партиясенең тәбәк бүлегеннән Рушания Бильгильдеева, "Россия Федерациясенең Коммунистлар партиясе" сәяси партиясенең Татарстан тәбәк бүлегеннән Хафиз Миргалимов, "Бердәм Россия" Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан тәбәк бүлегеннән Рөстәм Миннеханов, "ЛДПР-Россиянең либераль-демократик партиясе" сәяси партиясенең Татарстан тәбәк бүлегеннән Руслан Йосыпов.

Муниципаль сайлауларда шәһәр буенча 20 кандидат катнаша, аларның барысы да теркәлү узганнар инде. Кандидатларның төп өлеше "Бердәм Россия" партиясеннән күрсәтелгән, икесе – үз-үзләрен күрсәтүчеләр, икесе – "РФның Коммунистлар партиясе", берсе "Гадел Россия"дән.

Авыл җирлекләре Советларына 220 кеше үз кандидатурасын тәкъдим итте. Районның территориаль сайлау комиссиясе секретаре Галия Якупова әйтүенчә, хәзер эшче төркем тапшырылган документларны ТР Сайлау кодексы таләпләре буенча тикшерүне тәгәлләп килә.

15 августтан 12 сентябрьнең 0.00 сәгатенә кадәр телевидениедә һәм вакытлы басмаларда сайлау алды агитациясе үтә. Безнең газета дүшәмбе көнне сайлау алды агитациясе уздыру өчен түләүсез һәм түләүле басма мәйданнар бүлү буенча жирәбә уздыра. Газетага заявка биргән барлык теркәлгән кандидатлар да жирәбәдә катнаша ала.

Валентина ВАФИНА

**"КАЙНАР ЛИНИЯ"**

**ТР Үзәк сайлау комиссиясендә Татарстан Республикасы Президентын һәм ТР муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлаулары мәсьәләләре буенча "кайнар линия" эшен дәвам итә. Тел.: (843) 292-56-42, 292-85-14.**

ҺӨНӘРИ БӘЙРӘМ

## Наил Фазлыев: "Нурлат үсешенә эшлибез"




**Нурлат соңгы елларда зур төзелеш мәйданчыгын хәтерләтә.**

Нурлатка республикадан килүче зур кунаклар шәһәргә нәкъ әнә шундый бәяләмә бирә. Халыкның дуслыгы йорты, парк-скверлар, шәһәр мунчасы кебек сафка бастырылган яңа объектлар турында да район газетасы язды инде. Төзүчеләрнең ел башыннан бирле ирешелгән гомуми нәтиҗәләре турында район башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары **Наил ФАЗЛЫЕВ** белән сөйләшәбез.

**– Наил Нәгыймович, бүген республикада 30лап программа гамәлгә ашырыла, аларның күпчелеге инфраструктур үсеш белән бәйле. Аларда безнең район ничегрәк катнаша?**

– Актив. Мисал өчен, Кариев урамында "Социаль ипотека" программасы буенча 45 фатирлы торак йорт төзелеп бетеп килә. Яңа мәктәпкәчә урыннар булдыру программасы буенча 260 урынга балалар бакчасы төзелеше тәгәлләнү ягында. Бу объект булдырылачак урыннары буенча да, финанслау күләмнән да сокландырырлык, ул 141,7 миллион сум тәшкил итә. Исемлекне озак дәвам итеп булыр иде.

**– Капиталь ремонт программасы ярдәмендә шәһәрдәге күп кенә йортлар үзгәреш кичерде. Бу елга да масштаблы эшләр ниятләнгәнме?**

– Әлбәттә. Әлеге программа ярдәмендә подрядчылар 48,8 миллион сумга 15 күпфатирлы йортта капремонт ясадылар. Кайбер эшләр "Татнефть" компаниясе средстволарына да башкарылды, җәмгыять 25 миллион сум бүлеп бирде. Әлеге акчаларга без 10 күпфатирлы йортның түбәләрен ремонтладык. Төзүчеләр мәгариф объектларын капиталь ремонтлау буенча да яхшы эшләделәр. Шул көннәрдә 2нче, Фома, Колбай Мораса мәктәпләрендә эшләр тәгәлләнәчәк – аларны финанслау күләме 36 миллион сумлап тәшкил итә.

**– Быел спорт корылмаларына да шактый игътибар бирелде.**

– Әйе. Районда бу юнәлештәге программа да уңышлы тормышка ашырылып килә. Узган елларда файдалануга 6 спорт мәйданчыгы тапшырсак, быелның шул чоры эчендә президент программасы буенча шәһәр һәм авылларда 4 спорт корылмасы сафка басты инде. Тагы бер спорт мәйданчыгы Татарстан Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салихов инициативасы буенча төзелде.

**– Шәһәрдә төзелеш эшләре күләме күзгә күренерлек. Ә авыл җирлекләрендә, спорт мәйданчыкларыннан тыш, нинди объектлар барлыкка килде?**

– Күпфункцияле үзәкләр төзү программасы нигезендә, Каравыл Тавында 100 урынга авыл клубы төзелде. Кәкре Атау, Фомада модульле ФАПлар монтажланды, 7 авылның фельдшер-акушерлык пунктында җәмгысе 700 мең сумга капиталь ремонт тәгәлләнде. Нурлатта да район үзәк хастаханәсенең паталогоанатомик бүлеге бинасын модульдән кордык.

**– Наил Нәгыймович, районның инфраструктур үсеше торак һәм башка мөһим объектлар төзү белән генә чикләнми бит әле...**

– Без авылларны су белән тәэмин итү программасы буенча яхшы күрсәткечләр белән эшлибез. Мәсәлән, бүген Иске Чаллы, Яңа Тумба, Яңа Әлмәт һәм Киекледә су белән тәэмин итү буенча эшләр тәгәлләнеп килә. Сууткәргечләрнең озынлыгы 5,3 километр, гомуми бәясе 9,4 миллион сум. Шулай ук мәгариф объектларын җылылык белән тәэмин итү буенча эшләр алып барыла. Социаль әһәмияттәге объектларның җылыту системаларын капиталь ремонтлау программасы нигезендә, "Нурлат җылылык челтәрләре" җәмгысе 1,4 миллион сумга 3 объектта казаннарны алыштырды.

**– Яктырту белән эшләр ничегрәк?**

– Бу юнәлештә "Урамнарны яктыртуны торгызу" программасы актив тормышка ашырыла. 19 торак пунктта энергия саклаулы яктырткычлар куюга 5 миллион сум үзләштерелде инде, монда шәһәр дә, авыллар да кертелгән.

**– Юл төзелешенә дә тукталып узыйк әле...**

– Һәммәбезнең бәхетенә соңгы елларда юл төзелеше сизелерлек активлашты. Төрле юнәлешләрдәге автоюлларны, шулай ук ике күперне ремонтладык. Хәзер Базарлы Матак-Мамык-Чурабатыр-Кызыл Юл автоюлын төзү башланды, аның озынлыгы 5 километр, бәясе 5 миллион сум. Тукай поселогына 30 миллионга 2,5 километр юл төзелә. Муниципаль юл фонды средстволары хисабына шәһәрдә Кормыш, Йолдызлы, Кояшлы һәм башка урамнарда юллар ремонтланды. Шәһәр һәм авылларда якынча 4 километрлап юлга 20 миллион сумга каты өслек түшәлде. 26 мең квадрат метрдан артык юлларны ремонтлауга республика һәм җирле бюджетлардан 15 һәм 10,2 миллион сум бүлеп бирелде. Төньяк-Көнчыгыш микрорайонда 50 миллион сумга 3,5 километр озынлыктагы юл төзү эшләре тәгәлләнеп килә.

**– Җентекле җавапларыгыз өчен рәхмәт. Һөнәри бәйрәмегез алдыннан Нурлат төзүчеләренә теләкләрегез бардыр.**

– Бу данлы һөнәргә кагылышлы булган һәркемгә чын күңелдән нык сәламәтлек, иминлек телим, тармагыбыз нурлатлылар хакына чәчәк атсын иде.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

БЕР УЧ ХӘБӘР

### РЕСПУБЛИКА КӨНЕНӘ БҮЛӘК

**"Президент белән бергә!" республика иҗтимагый хәрәкәте Республика көненә багышлап игълан иткән "Безнең Республика: Без булдырабыз! Без бергә!" Туган көнең белән, Татарстан!" дип аталган балалар открыткалары конкурсы дәвам итә.**

– Конкурста 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр катнаша ала, - дип хәбәр итәләр "Президент белән бергә!" хәрәкәтенең Нурлат активистлары. – Катнашу өчен үз кулларың белән открытка ясарга, котлау тексты язарга кирәк, тышкы ягына исә "Безнең республика: Без булдырабыз! Без бергә!" һәм "Туган көнең белән, Татарстан!" дигән сүзләр язылган булырга тиеш. Район укучылары ясаган котлау открыткалары Республика көненә шәһәр һәм район халкына бүләк ителәчәк. Ә иң яхшы эшләр республика этабына юлланачак.

Открыткалар конкурсына коллектив эшләр дә кабул ителә. Ә открыткаларны 15 августка кадәр "Бердәм Россия" партиясенең Нурлат җирле бүлекчәсе башкарма комитетына (Пушкин ур., 46га) китерергә кирәк.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

### МӘКТӘПЛӘРНЕ КОМИССИЯ КАРАДЫ

**Район мәктәпләре арасында яңа уку елына иң яхшы әзерлеккә республика смотр-конкурсы узды.**

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы җәмәгать советы әгъзаларыннан торган эксперт төркеме ике көн дәвамында районда 7 мәгариф учреждениесендә булды. Комиссия мәктәпләрнең яңа уку елына әзерлеген тикшергәндә, аларның территорияләренә, төзекләндерүгә, яшел зоналарга, чәчәклекләргә, укыту-тәҗрибә участокларга кебек факторларга игътибар биргән. Моннан тыш, мәктәп бинасының техник һәм санитар торышы, янгын иминлеге, туклануны оештыру, спорт заллары һәм мәйданчыклары, медицина ярдәмен күрсәтү шартлары, социаль партнерлык та исәпкә алынган. Республика комиссиясе җиңүчеләрне "Иң яхшы авыл мәгариф учреждениесе", "Иң яхшы шәһәр мәгариф учреждениесе" һәм "Иң яхшы махсус (коррекцияләүче) учреждение" номинацияләрендә билгеләячәк.

### КАГЫЙДӘ ҺӘРКЕМГӘ БЕР

**Ерепкино авылында яшәүче җәяүле бер хатын-кыз машина астында калган, әстәвенә, 500 сум штраф та түләячәк әле.**

"Юлны тиешле булмаган урыннан чыгучы җәяүлеләр сәламәтлекләре турында уйламыйлар да. Кызганыч, җәяүлеләр катнашында һәлакәтләр еш-еш арта бара. Алар юл хәрәкәтендә тулы хокуклы катнашучылар һәм кагыйдәләрне бозган очракта, шоферлар кебек үк җаваплылыкка тартылалар. Моның өчен 500 сум штраф каралган", – ди ЮХИДИнең пропаганда ин-

### ТУЙЛАР ГӨРЛИ

Август аенда районда барлыгы 60 пар никахларын теркәргә планлаштыра. Бу ай – 2015 елда иң күп язылышу чоры икән.

### СКВЕРДА ЭШ ҖАНЛАНДЫ

Сәлимҗанов урамы 13нче йорт янындагы скверда төзекләндерү эшләре дәвам итә. "СтройГранд" подрядчы оешмасы иске скверны демонтажлап, хәзер яктырткычлар өчен кабельләр сузу белән мәшгуль, чиратта – поребриклар кую, брусчаткадан җәяүлеләр юлы ясау һәм яшелләндерү.

# НУРЛЫ ЯК

ИЛҺАМИЯ

## ӘТКӘЙ ГАРМУНЫ

*Әткәй сандыгында тальян гармун*
*Әткәй моңы, әнкәй сагышы,*
*"41"дә телдә бәгырьләрне*
*Кыңгыраулы гармун тавышы.*
*Сабантуйлар үтте авылымда*
*Ярсып дәртле көен уйнады,*
*"Әпипә"гә басты яшь килennәр,*
*Дөр селкенде мәйдан, тынмады.*
*Сабантуе үтте уйнап-көлеп*
*Әткәй моңы белән үрелеп,*
*Таң алдыннан кояш күтәрелдә*
*Ак болыты аша киерелеп.*
*Алсу таңның яңа хәбәреннән*
*Әянкәләр шашып елады.*
*Шушы көннән авыл урамнарын*
*"Герман" көе кат-кат урады.*
*Кыр капкасын үтте әткәй белән,*
*Яшь чылатты әнкәм күзләрен.*
*Киткән чакта гүя табигать тә*
*Елап юды синең эзләрне.*
*Киткән эзе калды олы юлда,*
*Әткәй генә кайтмый әйләнеп.*
*Тальян моңы сыза йөрәкләрне*
*Сугыш эзе белән бәйләнеп,*
*Әткәемнең тальян моңы әле дә*
*Кайтавазлар булып саклана,*
*Изге ядкәрендә оның уйный,*
*Әткәй күңеле, сизәм, шатлана.*

ӘЛФИЯ ТӨХФӘТУЛЛИНА

## АВЫЛЫМА...

Авылымның урамнары
Ямь-яшел чирәм иде,
Чит җирләрдә үтә гомер,
Сагынып үләм инде.

Авылымның кулләрендә
Үсә сары төнбоек
Шул күлләрдә йөзәр идем,
Төнбоекларын җыеп.

Авылымның инешендә
Чумып уйный кыр казы.
Шушы җырыма кушылган
Сагынуымның бик азы.

Авылымның аланында
Тулып пешә җиләкләр.
Кайларда гына булсак та,
Синдә безнең йөрәкләр.

Авылымның урманында
Тиен чикләвек яра,
Кичер, авылым, еш кайталмыйм,
Ерак шул безнең ара.

Игеннәр ишелеп уңа
Авылым кырларында,
Мин бәхетле сагынуымны
Әйтә алсам җырларымда.

## ЯШЬЛЕК ФӘЛСӘФӘСЕ

*Тормыш күгән иңләп кичкән чакта*
*Каерылды очар канатлар.*
*Аерым-аерым ике якта кешни*
*Безнең туйга җиккән пар атлар.*

*Бер-берләрен көтеп кешни алар,*
*Очрашулар эзләп аланда.*
*Мөлдерәмә сагыш күзләрендә,*
*Юксыналар икән алар да.*

*Мин күзәтеп йөрдем ул атларны,*
*Гомер узып киткән, сизмәдем.*
*Атлар утлап йөргән аланнарда*
*Синең эзләреңне эзләдем.*

*Зәңгәр кыңгыраулы аланнардан*
*Юкка чыкты атлар беркөнне.*
*Чәлпәрәмә килде хыяллары,*
*Икебезнең язмыш шикелле.*

ИЛСУР ЗӘЙДУЛЛА

## ЯЗМЫШ АСЫЛЫ

Нишлисең, бик кырыс бу язмыш,
Яшәүдә өметең булмагач...
Күкләргә, җирләргә үпкәләп,
Өзелә бер ялгыз сандугач.

Тигезсез юлларда абынулар,
Ялгышлар, төзәлмәс хаталар.
Үткәндә күңелсез бер көннәр
Киредән әйләнеп кайталар.

Йөрәккә һич җитми тынычлык,
Ялгызлык кимерә күңелне.
Талларда бер ялгыз сандугач,
Үткәннәр кабаттан бүгенге...

Югалткан дусларын, өметтән
Өзгәннәр якыннар, туганнар.
Күкләргә, җирләргә үпкәләп,
Әрнүдә көннәре узганнар.

## МӨГАЛЛИМӘЛӘР ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАША

**Дөресрәге, Заһид мәчете мөгаллимәләре. 5 еллык эш тәҗрибәләрен берләштерү инициаторы белән чыгучы һәм аны гамәлгә дә ашыручы – Рәисә Фәйзуллина.**

Озак еллар мәгариф системасында методист булып эшләгән Рәисә ханым дини гыйлем бирүдә дә тәҗрибә уртаклашу бик кирәкле эш дип санаган һәм үз кузаллавы буенча ярдәмлек төзеп тә куйган. Нурлат шәһәре мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов һәм Заһид мәчете имам-хатыйбы Нуриҗан хәзрәт Азизов фатихасы белән башланып киткән "Мәчет аһәңе" дигән китапка дәрес эшкәртмәләре, курсәтмә материаллар, мәчеттә үткәрелгән чаралардан фотолар кертелгән. Бирелә Пәйгамбәрләр тарихы, мөнәҗәтләр һәм мәдрәсәдә белем алучы шәкертләрнең фикерләре дә тупланган. Әлегә китап аз данәдә нәшер ителгән, финанс мәсьәләсе хәл ителгәндә, мөхтәсибәт аны барлык мәчетләргә дә таратырлык итеп бастырырга ниятли.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

СӘКИНӘ ХӘЙРУЛЛИНА

## ИЛАҺИ БЕР ТАНТАНА

Кулга –кул тотынышкан да
Юлга чыккан юкәләр.
Әйтерсең лә, тезелешеп
Олы кунак көтәләр.

Хуш ислардән баш әйләнә,
Чәчәгеннән бал тама.
Туган якта җәй белән яз
Кул бирешкән тантана.

Күкләрнең зәңгәрлегеннән
Елга суы көнләшә.

Чуар җанлы күбәләкләр
Гөлләр белән серләшә.

Яз сафлыгы, җәй җылысы
Табигатькә ягыла.
Язларымны эзләп, мин дә
Кайтам туган ягыма.

Хисләремнән баш әйләнә,
Күзләремнән моң тама.
Бу – күңел сәҗдәгә баскан
Илаһи бер тантана.

## ҖӘЙ УРТАСЫ

*Җәйнең кыл уртасы җитте,*
*Такыя урә болын.*
*Туйганчы сулыйсы килә*
*Яшел үләннәр тынын.*

*Иң рәхәт ямьле дөнья бу,*
*Иң-иң хозур патшалык.*
*Яланаяк чирәменнән*
*Атлап йөрим таң калып.*

*Туган җиремнең җылысы*
*Буыннарга тарала.*
*Сеял, диеп иңен куя*
*Мәхәбәт карт карама.*

*Җилдә тибрәлгән чәчкәләр*
*Серләшәләр шикелле.*
*Гөлбадран йөзенә яткан*
*Җәйнең сары сипкеле.*

*Шулчак кошлар җыр сузалар,*
*Яфраклар лепердәшә.*
*Җәйге урман, иркен болын*
*Сердәш булырга дәшә.*

*Чистарып кала күңелләр,*
*Яшәрүе бу җанның.*
*Әйтерсең, гомерләрнең дә*
*Кыл уртасында калдым.*

***



Чыклы үләннәрне ера-ера
Яланаяк атлыйм болыннан.
Син түгелме, гамьсез балачагым,
Узып киттең яңа кырымнан?

Җил тузгыткан сары чәчкәйләрең
Сыйпап үтте бугай битемне.
Пышылдадың әллә: бу кайтудан
Калыйм микән синдә, китимме?

Аннан көлдең чишмә чыңы булып,
Күбәләккә аннан әйләндең.
Өзелде дә шулчак тәгәрәде
Муенымдагы ап-ак сәйләнем.

Бер сискәнү җитте кайтарырга
Чынбарлыкка мине яңадан.
...Хыянәтчел кәккүк безнең яшьне
Бигрәк төгәл итеп санаган.



МИҢНЕРУЙ ГАЙФУЛЛИНА

## ЯЗМЫШ АСЫЛЫ

*Яланаяк йөрим иртән*
*Чәчәкләр арасында.*
*Бәллүр тамчылар тезелде*
*Керфегем карасына.*

*Чык суларында коенам,*
*Сандугач уятмыйча.*
*Үтә микән берәр минут*
*Сезләрне уйламыйча?*

*Чык суларына кагылсаң,*
*Томан булып коела.*
*Ярың сөеп җавап бирсә,*
*Бәхет шул күк тоела.*

## ПЕЧӘН ӨСТЕ

ИЛСУР ЗӘЙДУЛЛА

**Авыл өсләрендә печән исе,**
**Димәк, кемдер терлек асрый.**
**Ә бит күптән бетеп бара инде**
**Бу гадәте үткән гасырның.**

**Авыл өсләрендә печән исе,**
**Өмет бирә ярсу йөрәккә.**
**Колхоз чорларында калган нужа**
**Күп нәрсәгә безне өйрәткән.**

**Авыл өсләрендә печән исе,**
**Ул басылмый купме теләсәң.**
**Кипкән печән, бастырылкы олау,**
**Син төшемә минем керәсең!**

**Авыл өсләрендә печән исе,**
**Рәхәте бу июль аеның.**
**Шул рәхәттән, Ходай, килер көндә**
**Калдырмачы мине аерып.**

## ӘЙ, БУ ТОРМЫШ...

ФӘҮЗИЯ МӨХӘММӘТОВА

*Тигез юлда абындырып,*
*Үз каршында тезләндерә.*
*Кыска гына гомерне дә*
*Йөз төрлегә әйләндерә.*
*Бил бирмәскә тырышканны*
*Кыл урталай куя бөкләп.*
*Әй, бу тормыш! Авыр йөгең*
*Алабыз да иңгә йөкләп,*
*Эш атыдай җигеләбез –*
*Тормыш – ормыш, ни хәл итмәк?*
*Лаф орсак та, шул тормышны*
*Яратабыз, менә хикмәт!*

***

Турыга юл яру кыен да бит,
Ерып чыкмас көрткә уралып.
Хак-нахагын күтәргәннәр бара,
Үз-үзенә шулай юл ярып...
Тарту көчен җирнең тойган мәлдә,
Егәр алып җирнең үзеннән,
Баш күтәрми эшләгәннәр бара
Үзе салган сукмак эзеннән...
Күкрәк киереп, мал түшәлгән юлдан
Бара, кемнәр дөнья тоткасы?
Киңәйгәннән-киңәйгән ул юлның
Булмас, ахры, туктар ноктасы...

МАНЗАРА

БЕЗНЕҢ ТУРЫНДА

# “Нинди буласыгыз килә – шундый булыгыз”




**Таныш булыгыз: имиджмейкер Гүзәл Галләмова. Колбай Морасада урта мәктәп, Ижауда сәүдә техникумы, менеджмент белгечлеге буенча Россия Яңа университетын тәмамлаган.**

9 ел Ижауда “Леонардо” һәм “Пикассо” бутикларында директор булып эшләгән. Аннан киемнәр модасы дөньясында күбрәк белү теләге аны “Арт энд имидж” репутацион технологияләр институтына китергән. Танылган Россия имиджмейкеры Анна Чигиринскихта укыганнан соң 3 ел элек үз эшен ачып җибәргән. Бүген ул–Ижауда имиджын үзгәртергә, заманча образ булдырырга омтылучылардан үз төркемен һәм клиентларын булдырган имиджмейкер. Яңа агымны популярлаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары һәм зур сәүдә үзәкләре белән эшләүгә таяна. Аның белән аралашу безнең коллектив өчен дә кызыклы булды. Әңгәмәбездән сез дә файдалы киңәшләр алырсыз, дип уйлыйбыз.

**–Гүзәл, күп кешеләрдә киемгә кагылышлы уртак җитешсезлек нидән гыйбарәт?**

–Кеше үзенә бәя куя белми. Кызганычка каршы, без еш кына җитешсез якларыбызны күрсәтә, ә өстенлекле якларыбызны яшерә торган кием сайлыйбыз, шуңа үзбәябез дә түбән була. Ә үзбәясе түбән булган кеше бернинди эштә дә уңышка ирешә алмый. Мин клиентларыма шул гаделсезлекне төзәтергә, аларның матур якларына басым ясап, индивидуальлекләрен ачарга тырышам.

**– Ә бу җиңел эш түгелдер...**

– Юк, әлбәттә, еллар буе ныгыган стереотипны сындырырга туры килә бит. Әйтик, күп зур размерлы хатын-кызлар караңгы төстәге кием үзен төз күрсәтә, ә кыска буйлылар миңа һичшиксез үкчәле аяк киеме киярга кирәк, дигән фикер белән генә яшиләр һәм шуннан артыгын танырга да кирәксенмиләр. Ә бит кешенең образы төсләрдән генә түгел, аларның бер-берсен тулыландыруыннан, киемнең буеннан, муен уемыннан, фасоныннан, тукыма фактурасыннан, аксессуарлардан, макияждан һәм тагы әллә никадәр факторлардан туа. Әлбәттә, кешенең яше дә истә тотыла. Гардеробка һәр өстәлгән яңа кием очраклы гына алынырга тиеш түгел. Кеше кибеткә аерым максат һәм күзаллау белән барырга тиеш: бу киемне мин нәрсә белән кия алам, минем гардеробымда аны тулыландырырлык әйбер бармы... Әгәр шул сорауларга уңай җавап булмый икән, ул кулланылмаган киемнәр санын гына арттырачак. Мин клиентларымны андый ялгыштан сакларга өйрәтмәкче булам.

**– Ә клиентларыгыз һәрчакта да сезнең белән килешәләрме?**

–Аларның ахыр нәтиҗәне күреп, үзләренә бәя бирү мөмкинлекләре була бит. Мин, мәсәлән, төп эшкә керешкәнче, клиентның яшәү рәвешен, мөмкинлекләрен, нинди очрак өчен нәрсә теләгәнен ныклап өйрәнәм. Ул образ иң элек минем күзаллауда туа. “Образ под ключ” дигән төшенчә бар. Телеканаллардан “Модный приговор”, “Гардероб на вылет” кебек программаларны кызыксынып карамаган хатын-кыз сирәктер. Анда катнашучыларны һөнәрмән стилистлар әнә шул образга китерәләр. Ахыр чиктә анда гел һөнәрмәннәр вариантына өстенлек бирәләр. Безнең очракта да шулай. Нигездә безгә әнә шул образны эзләп тә таба алмаганнар мөрәҗәгать итә бит.

**–Гүзәл, өч ел эчендә әлеге тармакта нинди тенденция күзәтелә?**

–Кешеләр үз образларын эзләүдә кыюрак эш итәләр, һөнәрмәннәргә күбрәк ышана башладылар.

**–Нәрсә оталар һәм нәрсәдән арыналар?**

–Артык акча һәм вакыт сарыф итүдән, артык чүпрәк җыюдан котылалар. Үз-үзләрен ярата башлыйлар, максатчанлыклары, үз-үзләренә ышанычлары арта. Кием һәрчак кешенең кәефенә йогынты ясый.

**–Димәк, сез һәр очрак өчен дә алыштыргысыз берничә киңәш бирә аласыз:**

– Әлбәттә! Иң элек, караңгы төсләр белән артык мавыкмагыз. Ачык, якты төсләр кешенең кәефен күтәрә, энергиясен арттыра.

– Беркайчан кием ансамблен бер төсләрдән генә җыймагыз, анда һичшиксез сезнең өстенлекне ассызыклый торган “якты тап” булырга тиеш.

– Кием стиле һәр очрак өчен аерым сайлана. Һәр модалы кием Сезне модалы итә дигән фикер дөрес түгел. Уйланылмаган янәшәлеккә эләккәндә, иң модалы кием дә югалып калырга мөмкин.

– Сез нинди булырга телисез – шуңа ирешәчәксез. Матур һәм кабатланмас буласыгыз килә икән, сез һичшиксез шундый булачаксыз. Барысы да кәефтән һәм теләктән тора. Без шуларны ачарга ярдәм итүчеләр генә.

Сәкинә **НУРУЛЛИНА** сөйләште.

ШӘХСИ ХУҖАЛЫК

## ӘМЗӘДӘ ГИГАНТ КУЯННАР ҮСӘ

Иске Әмзәдән Илсур Хәйдәров гигант йорт куяннары үрчетә. Хәйдәровларның хуҗалыгында бүгенге көндә 60тан артыграк куян бар. Әмма гаилә башлыгы алга таба аларның санын күпкә арттырмакчы.

– Бүгенге көндә куяннар өчен сарай төзеп бетереп киләбез. Аннан оялар бүлергә кирәк булачак, – ди Илсур Хәйдәров.

Хәйдәровлар үз фермаларында нәселле куяннар үрчетмәкче. Бүгенге көндә хуҗалыкта ярымвеликан һәм Фландр токымлы куяннар асрала, хуҗа аларны эзләп Мамадышка кадәр барып җиткән. Бу ике токым да эре булулары белән аерылып тора, авырлыклары хәтта 12 килограммга кадәр җитәргә мөмкин, ди.

Хәйдәровлар шәхси ярдәмче хуҗалыкларында мөгезле эре терлек асрау белән дә шөгыльләнәләр. Куян асрау да Илсур өчен яңа нәрсә түгел, чөнки ул бала чагыннан бу эш белән мавыккан һәм йорт куяннарын күпләп үрчетү турында хыялланган.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

# Исән чакта күрешик...

ОЧРАШУ

**Яңа Әлмәт мәктәбе чыгарылышлары укытучыларында очраштылар.**

“Исән чакта күрешеп калыйк,
Җир астыннан юллар юк”–бу җыр сүзләрен берничә тапкыр кабатладылар сабакташлар очрашуына җыелучылар. Моннан 58 ел элек мәктәпне тәмамлаган, инде үзләре өлкәнлек бусагасыннан күптән атлаган апалар укытучылары Рәисә Исмәгыйлева янында истәлекләре белән кабат мәктәп елларын урадылар. Кырыс, әмма гадел, тирән белемле, тәрбияле сыйныф җитәкчеләре алар күңелендә шулай гомерлек остазлары булып кереп калган да бугай. Еллар үтсә дә, аның тәрбиясеннән тайпылмыйча, киңәшләреннән чыкмыйча яшәгәнгә, бүген һәр алты сабакташ та тормышта үз урыннарын тапканнардыр да әле. Нурлат, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләреннән, Иске Әмзә авылларыннан очрашуга килгән Исмегөл Лотфуллина, Мәдинә Ишкинеева, Әминә Кыямова, Рәисә Нурхәмитова, Вәсилә Минапова хезмәтне дә җигелеп тартканнар, тәрбияле балалар да үстергәннәр. Мәктәп елларында борын төрткән татулык, дуслык гомерлек булган: үзара элемтәне беркайчан өзмәгәннәр, очрашуларга җыелып, укытучыларының да




УКЫТУЧЫНЫҢ УРЫНЫ ӨСТӘЛ ТҮРЕНДӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ЙӨРӘК ТҮРЕНДӘ ДӘ

хәлен белешеп торганнар. Бу көнне дә күчтәнәчләр бирешеп, мәктәп елларын искә алып, мөгаллимәләренә рәхмәтләрен белдереп җан рәхәте алдылар алар.

– Хәтерлисезме...

– Безнең сыйныф иң дус, алдынгы булды, без Сез укырга киткән арада да йөзегезгә кызыллык китермәскә тырыша идек.

Шундый истәлекләргә куначкларның бүгенге тормышлары турында хикәятләр ялганды. Намуслы яшәгәннәр, үз һөнәрләрен табып дәрәҗәле хезмәт куйганнар, хәзер барысы да дин юлында. Телләрендә – балалары, оныклары, тормышка шөкерана итү. Әнә бит, яраткан укытучылары да бердәнбер кызы Алсу тәрбиясендә җәннәттәге кебек яши икән. Кышларын Казанда торса да, җәй җитү белән утарны хәтерләткән яшел чирәмле, гөлбакчалы туган йортына кайта Рәисә Хәнәфиевна. Биредә, авылдашлары арасында үткәргән һәр көне тәненә сихәт, җанына рәхәтлек бирә.

– Иң мөһиме, беребез дә тормышка зарланмый, шунысы куандыра, – ди Мәдинә Кыямовна истәлекләргә йомгак ясап. Ә укытучылары аларга сөеп карап туя алмый.

– Мин иң бәхетле укытучы,– ди еллар үтсә дә җетелеген җуймаган карашы белән аларны барлап. – Мондый акыллы, кешелекле укучылар миндә генә булды.

Ә саубуллашканда, ике елдан соң кабат очрашырга сүз куештылар. Чөнки ике елдан аларның сөекле апалары Рәисә Хәнәфиевнага туксан яшь, ә чыгарылышларның мәктәпне тәмамлауларына 60 ел тулачак.

Сәкинә **ХӘЙРУЛЛИНА**

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә дустыбыз **Рушания Мобин кызы Шакированың** 9 август көнне туган көне, гомер бәйрәме. Аңа 50 яшь тула. Аны юбилее белән котлап, теләкләрнең иң изгеләрен җиткерәбез. Көчле рухлы һәм кешелекле, юмарт һәм ярдәмчел, бәхетле һәм сәламәт бул! Ныклы тазалык, озын гомер, ак бәхетләр белән мул тормышта яшәвеңне телибез!

Туган көнең – юбилееә белән
Чын күңелдән сине
котлыйбыз,
Сәламәтлек,
шатлык-куанычлар,
Күңел тынычлыгы телибез.
Юлларыңа ак бәхетләр яусын,
Шатлык балкып
торсын йөзеңдә,
Кайгы-хәсрәт баш
очыңнан узсын –
Шул теләкләр бездән үзеңә!

**Иң изге теләкләр белән Рушания-Ришат Насыйбуллиннар.**

**Фома авылында** яшәүче кадерлебез **Рәхимҗан Слухан улы Сафинны** юбилее белән тәбриклибез.

Исәнлек, озын гомер, бәхетле картлык телибез.

**Туганнары, балалары, күршеләре.**

**Бикколда** туып, хәзер Нурлатта яшәүче кадерле улым, туганыбыз **Әхәт Зәкиулла улы Таһировны** 55 яшьлек юбилее белән ихлас котлыйбыз. Киң күңелле, олы йөрәкле, сабыр һәм тырыш туганыбызга шатлык-сөенечләрдән торган бәхетле тормыш, киленебез Рамилә белән тигез гомер кичерүләрен телибез. Балалар һәм оныклар рәхәте күреп, сау-сәламәт яшәгез.

Гади, сабыр, олы җанлы да син,
Кылганнарың бары изгелек.
Кайгыларсыз үтсен
һәрбер көнең,
Бәхетләрең булсын
гомерлек.

**Изге теләкләр белән әниең, апаң, энеләрең һәм аларның гаиләләре.**

Кадерле әниебез **Суфия Таһир кызы Кашапованы** 60 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз!

Бар тормышын хезмәткә, гаиләсенә багышлаган кадерле әниебезгә ныклы исәнлек, озын гомер телибез. Әтиебез Хәлим белән тигезлектә, муллыкта яшәп, безнең бәхеткә куанып, оныклар үстереп, тыныч тормышта яшәвегезне телибез.

Сабырлыгың, күркәм холкың белән
Дөньябызны безнең бизәдең.
Һәммәбезне сөеп, акыл белән
Тигезләдең яшәү бизмәнен.
Олы җанлы, мәрхәмәтле
булдың,
Кичерә белдең борчу
китерсәк.
Бар гамәлең, доган
безнең өчен,
Әниебез, сиңа зур рәхмәт!

**Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, балаларың, оныкларың.**

Коллегабыз **Гөлүсә Гәрәй кызы Садыйкованы** гомер бәйрәме – 55 яшьлек юбилее белән ихлас котлап, иң изге теләкләребезне җиткерәбез. Аңа бәхет-шатлыклар белән тулып торган озын гомер, саулык-сәламәтлек, бүгенгедәй яшь һәм мөлаем булып калуын телибез. Һәр көнең кояшлы, тормышың кайгы-хәсрәтсез үтсен.

Тормыш юлың һәрчак
балкып торсын,
Ягымлы, шат булсын күңелең.
Озын гомер,
бәхет-шатлык белән
Бер кайгысыз үтсен гомерең.
Һәр яңа көн бәхет алып килсен,
Алсу таңнар күмсен шатлыкка.
Яшәү дәрте янсын йөрәгеңдә,
Картаерга бер дә ашыкма.

**Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе коллективы.**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*2-этажный дом, ж/д, все есть. Т.: 8-937-600-48-07, 8-927-248-80-93.

*дом, ж/д. Т. 8-929-72-30-066.

*2-комнатная квартира, пер. Заводской. Т. 8-9274-14-73-97.

*2-комнатная квартира по ул. К.Маркса. Т. 8-937-576-02-84.

*магазин «Калейдоскоп» на продуктовом рынке. Т. 8-927-049-26-51.

*дом, с. Ст. Максимкино. Т. 8-927-246-68-94.

*магазин «Спорттовары и игрушки» на продуктовом рынке, готовый бизнес. Т. 8-927-049-26-51.

*дом на ж/д. Цена договорная. Т. 8-939-744-15-08.

*дом в д. Якушкино, газ, вода, свет. Участок 43 соток. Т. 8-912-757-13-80.

*участок 6 соток, старый дом, баня 250000 ж/д. Т. 8-927-428-21-12.

*1-комнатная квартира с индивидуальным отоплением. Т. 8-937-616-99-00.

*1-комнатная квартира, центр, ул. Школьная, 2 этаж, ремонт. Т. 8-927-434-17-84.

*дом, ул. Советская, 2500000, варианты. Т. 8-929-722-35-39.

*3-комнатная квартира, ул. Шашина. Т.: 4-37-60, 8-927-474-46-16.

*дом, ул. Кутузова, 1600 тыс.руб., коттедж, ул. Юбилейная, 3700 тыс. руб. Т. 8-929-727-12-82, Ксения.

*элитный коттедж, 6,2 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, центр, 3,6 млн.руб., 120 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*дом, с. Биляр-Озеро, 130 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*дом, д. Берлик, 100 кв.м, 350 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*дом, д. Курманаево, 160 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*дом, ул. Маслозаводская, 200 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*земельный участок, ул. Черемшанская, 120 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70. П/с 16-16-35/002/2013-381.

*3-комнатная квартира, новая, 70 кв.м, 3 этаж, 1,5 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*3-комнатная квартира, 5 этаж, мкр. Яшлек, 60 кв.м, инд.отопление. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, мансарда, 50 кв.м, 650 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*недостроенный дом, ул. Звездная, 100 кв.м, 950 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, ул. Нефтяников, 1 этаж, ремонт, 40 кв.м, 950 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, новая, 50 кв.м, 1 этаж, 1,2 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*комната в общежитии, 16 кв.м, 200 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*1-комнатная квартира, малогабаритная, центр, 500 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 1,150 тыс.руб., 2 этаж. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, ул. Садовая, 5 этаж, 50 кв.м, 820 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, ул. Ломоносова, 900 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 1,2 млн.руб., 3 этаж, 50 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, центр, ул. Синдрякова, 15, 2,850 тыс.руб., 150 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*дом. Т. 8-927-462-17-01.

*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 3 этаж, ремонт не требуется. Т. 8-927-439-69-54.

*дом. Т. 2-04-04.

*3-комнатная квартира, с/з, 3 этаж, школа рядом. Т. 8-927-672-09-14.

*1-комнатная квартира, Наб.Челны, 46-й комплекс, 30 кв.м. Т. 8-927-455-27-51.

*2-комнатная квартира в центре. Т. 8-927-423-80-69 (после 17.00).

*дом. Т. 8-937-287-73-83.

*дом. Т. 8-987-421-39-97.

*дом. Т. 8-927-041-39-93.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-21093», 2000 г/в, 50000, торг, срочно. Т. 8-937-589-83-21.

***"Lada-Priora", белая, 2013 г.в., все есть. Т.8-927-406-73-21.**

*«ГАЗель». Т. 8-929-729-45-36.

*»Калина» седан 2007 г.в. в хорошем состоянии, 2-ой хозяин. Т. 8-927-675-64-00.

*«Ока», в хорошем состоянии. Т. 8-927-465-35-90.

*«Дэу Нексия», 2012 г/в. Т. 8-927-423-42-53.

*"Лада Гранта", седан, 2013 г.в., автозапуск. Т. 8-927-436-89-05.

*«ВАЗ-2107», 2007 г/в. Т. 8-917-265-70-19.

*«ВАЗ-210740», 2011 г/в, пробег 60000, один хозяин. Т. 8-927-426-97-37.

## ДРУГОЕ

*сахар-2230, мука-970, магазин «Юмарт» . Т. 8-927-445-68-55.

*куры-молодки, бройлеры, несушки, утки, гуси. Т. 8-927-483-06-10. 8-917-293-27-47.

*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.

*доски осина, сосна, брусья 6 метров. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.

*ПГС, песок, глина, перегной, грунт от 3 т. Т. 8-927-424-02-83.

*памперсы (взрослые), второй размер. Т. 8-917-863-71-60.

*натуральный мед. Доставка. Т. 8-937-591-19-73.

*доски осина, сосна, брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.

*дрова. Т. 8-987-213-32-95.

*огурцы из личного подворья, оптом (от 5 кг), доставка. Т. 8-937-288-75-15.

*куры, утки, муларды. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.

*шкаф-купе, высота 2,4м, очень вместительный, книжный шкаф, б/у, кровать 1,5спальная. Т. 8-927-248-84-46.

*раковина с тумбой, мини-диван оранжевый, б/у. Т. 8-927-405-34-83.

*огнеупорный шамотный кирпич, б/у (230x110x65, 290x175x210x80); газовые баллоны, электроплита двухкомфорочная с духовкой, все в хорошем состоянии; листовое железо 1500x1500x0,05 пять листов. Т. 8-92-97-27-55-16.

*поросята (1,5 месяца), корова. Т.: 8-927-400-66-50, 8-917-392-69-24.

*бут.кирпичи, 2500 руб. Т. 8-937-600-49-27.

*стельная корова. Т. 8-927-402-08-51.

*перегной, бут, грунтощебень. Т. 8-927-463-63-17.

*батареи чугунные, б/у. Т. 8-927-672-09-14.

*телка, отел в феврале. Т. 8-927-455-03-99.

*козлята трехмесячные. Т. 8-927-046-15-77.

*ворота деревенские с калиткой. Т.: 2-37-87, 8-927-483-51-49, 8-927-470-18-48.

*велосипед многоскоростной. Т. 8-927-452-15-86.

*коляска-люлька (Италия), автокресло 0-13 кг. Т. 8-926-013-03-95.

*поросята. Т. 8-927-470-62-98.

*овца (на племя). Т. 8-927-426-36-29.

*поросята. Т. 8-937-770-46-59.

*мед с доставкой. Т. 8-927-448-04-76.

*бычки. Т. 8-927-987-87-63.

*печи для бани. Т. 8-927-047-39-53.

## ТРЕБУЕТСЯ

*в ООО «Перспектива» инженер ПТО, помощник бухгалтера, водитель «КамАЗа», каменщики, разнорабочие. Справки по тел.: 2-58-21, 2-58-24, по адресу: г.Нурлат, ул. Заводская, 1.

*на постоянную работу фрезеровщик, маляр (красильщик) металлоконструкций. Стаж обязателен. Т. 8-917-250-87-89.

*электромонтер. Т. 8-917-398-26-41.

*парикмахер. Т. 8-937-287-68-88.

*главный бухгалтер, о/р 3 года. Т.: 95-052, 8-937-772-26-30.

*в полицию электрик, сантехник (возможно совмещение). Т. 2-46-44.

*продавец, специалист по замене автомасел в магазин автозапчастей. З/п достойная. Т. 8-937-283-70-04.

*ООО «Промочистка» слесаря-сантехники (зарплата 15000 руб.), электрогазосварщик (зарплата 20000 руб.). Т. 2-03-29.

*водитель 1 класса. Требования: допуск на опасный груз, удостоверение на тахограф. Т. 8-937-575-28-16.

*мастера и бурильщики КРС. Т. 8-937-575-28-13.

*продавцы в продовольственный магазин. Т. 8-927-442-02-28.

*в ЭПУ «Нурлатгаз» слесарь по эксплуатации и ремонту газового оборудования, повар 4 разряда, слесарь КИПиА 5 разряда, электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования 5 разряда. Адрес: ул. Гиматдинова, 158. Т. 2-14-03.

*повар. Т. 8-927-427-79-97.

## РАЗНОЕ

*ремонт пластиковых окон, москитных сеток. Т. 8-927-249-54-24.

*услуги электрика. Т. 8-937-614-70-15.

*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.

***КРОВЛЯ И ВСЕ ВИДЫ СТРОИТЕЛЬНЫХ РАБОТ. БЫСТРО И КАЧЕСТВЕННО. Т. 8-927-422-26-33.**

*тамада. Т. 8-960-088-23-94.

*установка окон, дверей, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.

*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*г/п. Т. 8-927-401-11-76.

*ремонт, настройка компьютеров, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-0051-451.

*ежедневно Нурлат-Самара автовокзал, глазные клиники. Т. 8-927-031-29-33.

*копаем, чистим колодцы, заливаем фундаменты. Т. 8-927-481-51-72.

*копаем, заливаем фундамент; услуги каменщика. Т. 8-937-294-65-52.

*копаем, чистим колодцы, копаем траншеи, канализации. Т. 8-937-776-79-45.

*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.

***кровля, штукатурка, вагонка, бетонные работы. Т. 8-917-865-30-35.**

*копаем, заливаем фундамент, копаем траншеи (водопровод). Т. 8-937-589-51-73.

*«ГАЗель». Т. 8-927-406-83-84.

*обучаю игре на гитаре. Т. 8-937-770-72-52.

*искусственное осеменение коров. Т.: 8-927-455-47-56, 3-45-02 (с 13.00 до 18.00).

*копаем, заливаем фундаменты. Т. 8-927-419-89-28.

## КУПЛЮ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.

*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.

*баллоны кислородные, углекислотные. Т. 8-987-292-01-10. ООО «ГК «Втормет».

*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.

*авто в любом состоянии на авторазбор. Т. 8-927-246-51-99.

*участок. Т. 8-927-413-86-26.

*пух гусиный (мокрый, сухой), старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.

*закупаем молоко. Т.: 90-135, 90-119.

*овец. Т. 8-937-600-49-27.

## СДАЮТСЯ

*в парикмахерской в аренду рабочие места. Т. 8-937-287-68-88.

*квартира посуточно. Т. 8-927-456-05-69.

## ПОТЕРИ

*утерянный аттестат Б №899448 о среднем (полном) общем образовании, выданный Кульбаево-Марасинской средней школой в 1983 г. на имя Раили Касимовны Уразгильдеевой, считать недействительным.






12+ "ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә

**10 АВГУСТ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**12 АВГУСТ**
"Нурлат хәбәрләре",
"Татнефть" хәбәрләре.

**14 АВГУСТ**
"Нурлат хәбәрләре".
"Сиңа дигән җырым", музыкаль тапшыру

Программалар **19 сәгатьтә** башлана. **11, 13, 15 августта** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.


**ДВЕРИ ЭКОНОМ**
сеть дверных магазинов

**ВХОДНЫЕ, МЕЖКОМНАТНЫЕ, БАННЫЕ ДВЕРИ.**

*Доставка в кратчайшие сроки (от 1-2 дней). Установка.*

Цены г.Самары и Казани.
Ул. Гиматдинова, 52, 1 этаж (вход в БТИ).

**8-937-583-45-17, 8-927-439-17-06.**

Реклама


## Кайгы уртаклашабыз

"Нурлат" телерадиокомпаниясе коллективы, тормыш иптәше һәм әтисе вакытсыз вафат булу сәбәпле, коллегалары – **Нурия Попкова һәм Лилия Зәйнуллинаның** авыр кайгыларын уртаклашалар, хәсрәтле көннәрендә сабырлык һәм түземлек телиләр.

***

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы редакциясе коллективы, тормыш иптәше һәм әтисенең вакытсыз вафат булуы сәбәпле, "Нурлат" ТРКсы баш бухгалтеры **Нурия Попкованың һәм кызы Лилия Зәйнуллинаның** авыр кайгыларын уртаклашалар һәм сабырлык телиләр.

